Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге составына керүче
Чаллыбаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

24 ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 24 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: “Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Чаллыбаш авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:
- Чаллыбаш торак пунктында сууткәргеч челтәрләрне ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү (запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
- Чаллыбаш торак пунктында су белән тәэмин итү системасы эчтәлеге (тирән насослар сатып алу);
- Чаллыбаш торак пунктында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү – килешү буенча);
- Чаллыбаш т. п. да урамнарның юл өлешен кышкы чорда кардан чистарту (урамнарны чистарту) ;
- Чаллыбаш торак пунктында 4 данә чүп контейнерлары сатып алу;
- Чаллыбаш торак пунктында БВС һәйкәлен ремонтлау;
-Чаллыбаш торак пунктында су белән тәэмин итү системасын рәсмиләштерү.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 96 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 68 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 68 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге составына керүче Чаллыбаш авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: “Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Чаллыбаш авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:
- Чаллыбаш торак пунктында суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү (запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
- Чаллыбаш торак пунктында су белән тәэмин итү системасы эчтәлеге (тирән насослар сатып алу);
- Чаллыбаш торак пунктында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү – килешү буенча);
- Чаллыбаш т. п. да урамнарның юл өлешен кышкы чорда кардан чистарту (урамнарны чистарту) ;
- Чаллыбаш торак пунктында 4 данә чүп контейнерлары сатып алу;
- Чаллыбаш торак пунктында БВС һәйкәлен ремонтлау;
-Чаллыбаш торак пунктында су белән тәэмин итү системасын рәсмиләштерү.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Биектау авылы, Х. Сафиуллин урамы, 4 йорт; Околоток-Яңасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт; Чаллыбаш авылы, М. Горький урамы, 69 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Гилазиева А.Р.

Биектау авыл җирлеге башлыгы: Гилазиева А.Р.